Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының

Югары Чура авыл җирлеге Советы

КАРАР

11 июнь 2024 ел № 23

Югары Чура авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлı Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында ү вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирл үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрне контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыр нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарста Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрла Кабинеты карары нигезендә Югары Чура авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Югары Чура авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмар муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең вәкаләтләрн даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулı вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өче түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) Югары Чура авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 ноябрендәге 2 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 2 декабрендәге 37 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрн исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләме (сумнарда |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 ме кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 18 260 |

б) 3.1 пунктының беренче абзацында «12688» санын «13323» санына алыштырырга;

в) Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Муниципаль хезмәткәркә вазыйфаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата түләүләр түләнә, җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле муниципаль хезмәткәрне элек билгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфаи окладлы муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую очрагыннан тыш, бу очракта акчалата түләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакын элек ул билгән вазыйфалары буенча акчалата хезмәт хакы күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла».

г) 4 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 41 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Югары Чура Авыл җирлеге
башлыгы урынбасары А.Н.Афанасьев